СОВЕТ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27.08.2020 г. Заинск № 555

**«Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнарында эшләүче муниципаль хезмәткәрләр булмаган белгечләрнең һәм эшчеләрнең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында» 2018 елның 13 апрелендәге 280 номерлы Зәй муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

1998 елның 31 июлендәге 145-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында» 2020 елның 5 августындагы 655 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. «Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнарында эшләүче муниципаль хезмәткәрләр булмаган белгечләрнең һәм эшчеләрнең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында» 2018 елның 13 апрелендәге 280 номерлы Зәй муниципаль районы Советы карары белән расланган Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнарында эшләүче муниципаль хезмәткәрләр булмаган белгечләрнең һәм эшчеләрнең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәнең 2.2 пунктына үзгәреш кертергә, «11163 сум» сүзләрен «11498 сум» сүзләренә алмаштырырга.
2. Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә штат расписаниеләренә һәм локаль актларга тиешле үзгәрешләрне кертергә.

3. Зәй муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Карар 2020 елның 1 октябреннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы башлыгы урынбасары В. Г. Акатьевка йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**